ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.11.2022 Казан ш. № 657-25/э-2022

Татарстан Республикасы территориясендә ваклап сату базарын электр энергиясе (егәрлеге) белән тәэмин итүче «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыяте электр энергиясен гарантияле тәэмин итүчегә 2023 елга сату өстәмәләре билгеләү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасы өлкәсендә бәя куюы турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Аналогларны чагыштыру ысулын кулланып, гарантияле тәэмин итүчеләрнең сату өстәмәләрен исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2017 елның 21 ноябрендәге 1554/17 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 18 ноябрендәге 39-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә ваклап сату базарын электр энергиясе (егәрлеге) белән тәэмин итүче «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыятенең электр энергиясен гарантияле тәэмин итүчегә сату өстәмәләре билгелргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасы территориясендә ваклап сату базарын электр энергиясе (егәрлеге) белән тәэмин итүче «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыяте электр энергиясен гарантияле тәэмин итүчегә 2022 елга сату өстәмәләре билгеләү хакында» 17.12.2021 № 681-33/э-2021 карарын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.11.2022 № 657-25/э-2022
карарына кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә ваклап сату базарын электр энергиясе (егәрлеге) белән тәэмин итүче «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыятенең электр энергиясен гарантияле рәвештә җиткерүчесенә 2023 елга сату өстәмәләре (тарифлар өстәмә хак салымыннан тыш күрсәтелгән)

сум/кВт·сәг

| т/с | Оешма атамасы | Сату өстәмәсе | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | халык һәм аңа тиңләштерелгән кулланучылар категорияләре | югалтуны компенсацияләү өчен электр энергиясен сатып алучы челтәр оешмалары | үзләренә караган энергия кабул итү җайланмаларының максималь егәрлеге 670 кВт ким булмаган башка кулланучылар | үзләренә караган энергия кабул итү җайланмаларының максималь егәрлеге 670 кВт башлап 10 МВт кадәр булган башка кулланучылар | үзләренә караган энергия кабул итү җайланмаларының максималь егәрлеге кимендә 10 МВт булган башка кулланучылар |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 1. | «Татэнергосбыт» акционерлык җәмгыяте | 0,5767 | 0,2756 | 0,0965 | 0,0919 | 0,1754 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге